**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СУЫКСУ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

**СОВЕТ СУКСИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная., 9а

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**21 сентябрь 2020 ел.** **№ 1**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты, 43 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм хисап комиссиясенең 2020 елның 21 сентябрендәге 2 номерлы беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. “Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм 7 нче номерлы Суыксу бермандатлы сайлау округы депутаты, Суыксу авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Советы рәисе итеп Низамиев Рамил Сәлим улын сайларга.
2. Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешү көне итеп, аны Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көн дип санарга.
3. «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Суыксу авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Низамиев Рамил Сәлим улын Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куярга.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгүлүмат порталының рәсми сайтында: http:// http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Утырышта рәислек итүче
6 нчы номерлы сайлау округы депутаты Ә.Г.Усманов